1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте концепциясен раслау турында» 2008 елның 3 июлендәге ПУ-312 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 26 июлендәге ПУ-695 номерлы, 2019 елның 6 маендагы ПУ-259 номерлы указлары, Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 6 апрелендәге 213 номерлы һәм 2023 елның 5 июнендәге 386 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте концепциясенә, аны кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2026 ел, 16 май
№ 393

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2026 елның «16» маендагы
393 номерлы Указына
кушымта

# Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте
# КОНЦЕПЦИЯСЕ

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте концепциясе (алга таба – Концепция) сәяси-хокукый карашларның, рухи хәзинәләр, принциплар һәм өстенлекләрнең системага салынган җыелмасыннан гыйбарәт, Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары эшчәнлеген (алга таба – дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары), аларның граждан җәмгыяте институтлары белән хезмәттәшлеген координацияләү өчен нигез хезмәтен үти.

2. Концепция – Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтенең максатын, принципларын, өстенлекле юнәлешләрен һәм аның өстенлекле юнәлешләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү бурычларын, шулай ук аны гамәлгә ашыруның ысулларын һәм механизмнарын билгели торган документ.

3. Концепция дәүләт, җәмгыять, кеше һәм граждан мәнфәгатьләрен тәэмин итү, Россия Федерациясенең дәүләт бердәмлеген һәм бөтенлеген ныгыту, Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең этник-мәдәни үзенчәлекләрен саклау, милләтара (этносара) мөнәсәбәтләрне җайга салу максатларында эшләнде.

4. Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше, илкүләм иминлекне тәэмин итү, экстремистлыкка каршы көрәшү, Россиянең традицион рухи-әхлакый хәзинәләрен саклау һәм ныгыту, төбәк үсеше, мәгариф, тышкы, мәдәни, тел, яшьләр һәм миграция сәясәте өлкәләрендә норматив хокукый актлар, шулай ук дәүләт милли сәясәте өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала торган башка документлар, Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасындагы шартнамәләр (килешүләр) Концепциянең хокукый нигезен тәшкил итә.

5. Концепция Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең тарихи гореф-гадәтләрен, табигать-климат шартларын һәм табигый-икътисадый шартларны, алар тормышының социаль-мәдәни үзенчәлекләрен, геосәясәт һәм милли мохитне, халыклар хезмәттәшлеге һәм багланышлары тәҗрибәсен аңлауга, гомумроссия гражданлык тәңгәллеге (гражданлык үзаңы) һәм бердәмлек формалашуга йогынты ясаган төбәктәге әһәмиятле вакыйгалар турындагы хәтергә таяна һәм Татарстан Республикасында хәзерге этник-социаль вазгыятьне чагылдыра.

6. Концепция республикада гомуми социаль, сәяси һәм икътисадый тотрыклылыкны тәэмин итүгә, дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары, граждан җәмгыяте институтларының нәтиҗәле үзара хезмәттәшлегенә, Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның этник-мәдәни үзенчәлекләрен саклауга, милләтләр һәм гражданнар арасындагы тынычлык һәм татулык, диннәргә бертигез караш һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең этник-мәдәни яктан бер-берсен баетуы традицияләрен үстерүгә, кеше һәм гражданның конституциячел хокуклары үтәлүен тәэмин итүгә, дәүләт милли сәясәте өлкәсенә кагылышлы максатчан проектларны һәм дәүләт программаларын эшләүгә һәм гамәлгә ашыруга юнәлтелгән.

7. Концепция дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары, шулай ук граждан җәмгыяте институтларының Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте мәсьәләләрен хәл итүгә бердәй карашын булдыру өчен нигез хезмәтен үти.

8. Концепция комплекслы тармакара социаль юнәлешле булып, Россия Федерациясе күпмилләтле халкының (Россия милләтенең) мөмкинлекләрен үстерүгә һәм гомумроссия граждан тәңгәллеген (гражданлык үзаңын) ныгытуга юнәлтелгән.

## II. Татарстан Республикасында милләтара (этносара) мөнәсәбәтләрнең хәзерге торышы

9. Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте түбәндәге төп өстенлекле нигезләмәләргә таянып алып барыла: Россия Федерациясенең дәүләт бердәмлеген һәм бөтенлеген ныгыту, Татарстан Республикасында яшәүче барлык халыклар вәкилләренең тормышы һәм этник-мәдәни үсеше өчен бертигез шартлар булдыру, шулай ук Татарстан Республикасыннан читтә – тарихи шартларда барлыкка килгән төп яшәү урынында көн күрүче татар халкына төрле яклап ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү зарурлыгы.

10. Татарстан – күпэтнослы һәм күпконфессияле республика, аның үсешенә хәзерге Татарстан территориясендә яшәүче халыклар вәкилләренең тыгыз этник-мәдәни үзара йогынтысы һәм гореф-гадәтләренең үзара нык үрелгән булуы хас. Бу процесста Татарстан Республикасында яшәүче барлык башка халыклар вәкилләре белән чагыштырганда тарихи нигездә барлыкка

килгән күпчелекне тәшкил итүче татар һәм рус халыклары вәкилләре традицион рәвештә әйдәүче роль уйный. 2020 елгы Бөтенроссия халык санын исәпкә алу йомгаклары буенча Татарстан Республикасында 4 004,8 мең кешенең 53,6 процентын татарлар, 40,4 процентын руслар тәшкил итә. Идел буенда яшәүче халыклар вәкилләреннән Татарстан Республикасы территориясендә чувашлар, удмуртлар, мордвалар, марилар һәм башкортлар яши.

11. Хәзерге Татарстан территориясендә җирле җәмәгатьчелекнең тарихи нигездә милләтләр (этнослар) арасындагы һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләрнең дустанә рухта булуы хас аерым бер төре барлыкка килде. Бик зур тарихи чор дәвамында бергәләп яшәү барышында күркәм күршелек, диннәргә тигез караш, милләтләр (этнослар) арасындагы дуслык һәм хезмәттәшлекнең тотрыклы сыйфатлары формалашты. Гореф-гадәтләргә таяну, республикада милләтләр һәм диннәр арасындагы тынычлыкның һәм үзара аңлашуның юкка чыгуына юл куймыйча, тискәре сәяси, милли-радикаль тенденцияләр йогынтысын бетерергә, экстремистлык очракларына каршы көрәшергә мөмкинлек бирә.

12. Төрле төрки һәм фин-угор компонентларын тарихи нигездә үз эченә алган, соңрак славян йогынтысын кичергән татар халкының мең елдан артык дәүләтчелек тарихы бар, аның турындагы күзаллаулар татар халкы тәңгәллегенең аерылгысыз өлеше булып тора, милли-дини үзаңы үсешенә этәргеч бирә, күпчелек очракта татарларның башка халыклар белән үзара мөнәсәбәтләре эчтәлеген һәм характерын билгели. Шул ук вакытта татар халкының үсеше үзенчәлеге аның территориаль яктан бүленгәнлеген китереп чыгарды. Шуның нәтиҗәсендә Татарстан территориясендә бүген татарларның гомуми саныннан өчтән береннән азрагы гына яши, бу исә республикадан читтә яшәүче татарларның этник-мәдәни мәнфәгатьләре, теләкләре һәм ихтыяҗлары исәпкә алынган дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру зарурлыгын китереп чыгара. Шул сәбәпле Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтендә теге яки бу күләмдә барлык татар халкының этник-мәдәни казанышларын саклау, үстерү һәм баету мәсьәләләре урын алган.

13. Татарстанның күпмилләтле халкы барлыкка килүе һәм үсешенә рус халкы вәкилләре зур йогынты ясады. Рус халкы вәкилләренең этник-мәдәни үсешенә кагылышлы хәзерге Россия өчен уртак булган мәсьәләләр Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтенең аерылгысыз бер өлеше булып тора.

14. Хәзерге Татарстан территориясе борынгыдан ук монда традицион тупланып яшәү җирлекләренә ия булган төрле халыклар вәкилләренең гомер итү урыны булып тора һәм, нәтиҗә буларак, алар үз этник мәдәни, милли тел һәм милли-мәгариф ихтыяҗларын тиешле институтлар һәм учреждениеләр аша дәүләт тәэмин итүенә мохтаҗ.

15. Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен формалаштыруга һәм гамәлгә ашыруга миграция процесслары билгеле бер йогынты ясый. Социаль-икътисадый үсеш, этнослар һәм конфессияләр арасында дустанә мөнәсәбәтләр урнашу нәтиҗәсендә мигрантлар агымының көчәюе республикага килгән гражданнарның социаль җайлашуын тәэмин итү өчен, Россиянең традицион рухи-әхлакый хәзинәләренә таянып, чаралар эшләү шартын куя.

16. Татарстан Республикасында милләтара (этносара) мөнәсәбәтләрнең хәзерге торышына, гомумән алганда, тотрыклылык, төрле милләт һәм дин вәкилләренең тыныч рухтагы мөнәсәбәтләре һәм хезмәттәшлеге хас.

17. Шул ук вакытта милләтләр (этнослар) һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләр өлкәсендә русофобия, неонацизм, тарихны бозып күрсәтү, Россия милләтенә чит булган идеалларны һәм рухи хәзинәләрне тагу күренешләре, безгә каршы булган чит илләрнең милләтләр (этнослар) һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләрне какшатырга тырышуы белән бәйле яңа хәвеф һәм сынаулар барлыкка килү куркынычы бар.

18. Концепцияне гамәлгә ашыруның узган чорында Татарстан Республикасында милләтләр, диннәр арасында тынычлыкны һәм татулыкны тәэмин итүдә җитди уңышларга ирешелде. Социологик сораштырулар йомгакларына караганда, 2025 елда республика халкының 86,5 проценты Татарстанда милләтләр (этнослар) арасындагы мөнәсәбәтләр, 84,2 проценты диннәр арасындагы мөнәсәбәтләр торышын уңай бәяли, республика халкының якынча 90 проценты милли, тел яисә дини билгеләренә бәйле рәвештә үзләренә карата дискриминация тоймауларын билгели, ә гомумроссия һәм Татарстан гражданлык тәңгәллеге 86 процент тәшкил итә.

## III. Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруның максатлары, принциплары, өстенлекле юнәлешләре һәм бурычлары

19. Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтенең максаты – республиканың тотрыклы үсешен саклау, шулай ук аның социаль һәм икътисадый тотрыклылыгын тәэмин итү өчен этник-мәдәни һәм телләр күптөрлелеген саклап аның күпмилләтле халкы бердәмлеген, гомумроссия гражданлык тәңгәллеген (гражданлык узаңын) ныгыту.

20. Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте принциплары түбәндәгеләр:

а) кешенең һәм гражданның расасына, милләтенә, теленә, килеп чыгышына, милкәти һәм вазыйфаи хәленә, тору урынына, дингә мөнәсәбәтенә, инануларына, нинди җәмәгать берләшмәсенә керүенә һәм башка шартларга карамастан, аның хокуклары һәм ирекләре тигезлеге;

б) Татарстан Республикасында яшәүче барлык халыклар (этник берлекләр) вәкилләренә үсеше өчен бертигез шартлар тәэмин итү;

в) гражданнарның милли абруен ихтирам итү, расачыл, милли һәм дини нигезгә корылган нәфрәт яисә дошманлык кабызу омтылышларын кисәтү һәм туктату;

г) Татарстан Республикасы территориясендә этник-мәдәни күптөрлелеккә һәм телләр күптөрлелегенә, аның күпмилләтле халкының республика һәм, гомумән алганда, Россия җәмгыятенең киләчәк үсеше мөһим стратегик ресурсы булган иҗади потенциалына дәүләт ярдәме күрсәтү.

21. Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтенең өстенлекле юнәлешләре түбәндәгеләр:

а) Россиянең традицион рухи-әхлакый һәм мәдәни-тарихи хәзинәләренә нигезләнеп гражданлык бердәмлеген, гомумроссия гражданлык тәңгәллеген (гражданлык үзаңын) һәм аның контекстында формалаштырыла торган Татарстан гражданлык тәңгәллеген ныгыту;

б) рус телен саклау һәм аны Россия Федерациясенең дәүләт теле, туган тел һәм милләтара аралашу теле буларак файдалануны тәэмин итү, рус халкының дәүләт төзүче халык буларак берләштерү ролен ныгыту;

в) татар телен Татарстан Республикасының дәүләт теле һәм туган тел буларак саклау һәм үстерү;

г) Татарстан Республикасында яшәүче барлык халыклар вәкилләренең телләрен, мәдәниятләрен һәм гореф-гадәтләрен, Татарстан Республикасында этник-мәдәни күптөрлелекне һәм телләр күптөрлелеген саклау һәм аларның үсешенә ярдәм күрсәтү, анда яшәүче барлык халыкларның рухи берлеген ныгыту;

д) милләтләр (этнослар) һәм диннәр арасындагы тынычлыкны һәм татулыкны тәэмин итү, экстремистлыкка һәм милли (этник) һәм (яисә) дини җирлектә низаглар килеп чыгуга каршы көрәшү;

е) Татарстанны татар халкының рухи һәм этник-мәдәни үзәге буларак тану, Татарстан Республикасыннан читтә яшәүче татарларга аларның интеллектуаль, икътисадый һәм этник-мәдәни берләшүе һәм аларга ярдәм күрсәтү өчен шартлар тудыру;

ж) чит илләрдә яшәүче ватандашларга ярдәм күрсәтү, аларның Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы белән элемтәләрен үстерүгә һәм Россия Федерациясенә (Татарстан Республикасына) ирекле рәвештә күченүләренә булышлык күрсәтү.

22. Россиянең традицион рухи-әхлакый һәм мәдәни-тарихи хәзинәләренә нигезләнеп гражданлык бердәмлеген, гомумроссия гражданлык тәңгәллеген (гражданлык үзаңын) һәм аның контекстында формалаштырыла торган Татарстан гражданлык тәңгәллеген ныгыту түбәндәге бурычларны хәл итү аша башкарыла:

а) аеруча балаларда һәм яшьләрдә белем һәм тәрбия бирү процессларының барлык этапларында бердәм милли-дәүләти үзаң (гомумроссия һәм аның контекстында формалаштырыла торган Татарстан гражданлык тәңгәллеге) һәм ватанпәрвәрлек формалаштыру, шул исәптән:

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт символларының балалар һәм яшьләр иҗтимагый тормышының барлык өлкәләрендә кулланылуын тәэмин итү һәм белем һәм тәрбия бирү процессларының барлык этапларында дәүләт символикасына ихтирамлы мөнәсәбәт булдыру;

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт бәйрәмнәренә, истәлекле даталарга һәм истәлекле көннәргә багышланган һәм балаларда һәм яшьләрдә бергәлек, илнең, шулай ук республиканың тарихына, гомуми тарихи мирасның аерылгысыз бер өлеше буларак, аның казанышларына катнашы булу хисен тудыручы чаралар оештыру һәм уздыру;

туган як тарихын өйрәнүне үстерү, балаларның һәм яшьләрнең мәдәни мирас объектларында (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре), истәлекле урыннарда, халыкның хезмәт батырлыгын чагылдыра торган объектларда булуын оештыру;

төрле буыннарның якынаюына һәм Россиянең традицион рухи-әхлакый хәзинәләрен өлкән буыннан яшь буынга тапшыруга, гражданлык бердәмлеген ныгытуга, яшьләрнең Россия халыкларының, шул исәптән вәкилләре Татарстан Республикасында яшәгән халыкларның да, мәдәнияте һәм гореф-гадәтләре белән танышуына юнәлтелгән проектлар булдыру һәм аларны үстерү;

балалар һәм яшьләр арасында ксенофобия, нацизм идеологиясе, экстремистлык һәм террорчылык таралуга каршы көрәшүгә юнәлтелгән чаралар оештыру һәм уздыру;

белем бирү эшчәнлеге алып баручы оешмалар гамәлгә ашыра торган мәгариф программаларына Россиянең традицион рухи-әхлакый һәм мәдәни-тарихи хәзинәләре белән танышу буенча уку предметлары, курслар, фәннәр (модульләр) кертү;

вәкилләре Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның гражданнар бердәмлеген һәм татулыгын ныгытуга йогынты ясаган, ил тарихы өчен әһәмиятле вакыйгалар барышындагы тарихи бәйләнешләры тәҗрибәсе белән танышу буенча белем бирүнең төрле дәрәҗәләрендә мәгариф программаларын, шулай ук укыту-методика комплексларын камилләштерү;

Татарстан Республикасының этник-мәдәни үзенчәлекләрен исәпкә алып, педагогика хезмәткәрләренә һөнәри белем һәм өстәмә һөнәри белем бирү;

б) милләтләр (этнослар) арасындагы мөнәсәбәтләр культурасын саклау һәм үстерү, тарихи дөреслекне һәм тарихи хәтерне, Россиянең традицион рухи-әхлакый һәм мәдәни-тарихи хәзинәләрен яклау, шул исәптән:

ватанпәрвәрлек, Ватанга хезмәт итү һәм аның язмышы өчен җаваплылык, милләтләр (этнослар) арасында татулык идеяләрен раслау;

җәмгыятьтә неонацизмны, расизмны, экстремистлыкны һәм ксенофобияне, нинди дә булса бер милләтнең башкалардан өстенлеген кабул итмәүгә, аларны пропагандалауга һәм аклауга юл куймауга юнәлтелгән карашларны тарату;

Россия һәм Татарстан тарихының, дәүләт төзүче рус халкының, татар халкының һәм Татарстан Республикасында яшәүче башка халыкларның тарихын да кертеп, әһәмиятле вакыйгалары турындагы дөрес һәм фәнни нигезләнгән тарихи белемнәрне популярлаштыру;

илнең бердәм мәдәни киңлеген үстерү, мәдәни һәм милләтара хезмәттәшлек өлкәсендә төбәкара хезмәттәшлек механизмнарын үстерү;

тарихны, дәүләт бәйрәмнәренә, истәлекле даталарга һәм истәлекле көннәргә нигез булган әһәмиятле тарихи вакыйгаларны өйрәнүгә, шул исәптән архив документларын популярлаштыру юлы белән дә, кызыксынуны арттыру;

гомумроссия гражданлык тәңгәллеге (гражданлык үзаңы) нигезе буларак, Россиянең традицион рухи-әхлакый хәзинәләрен саклауга һәм ныгытуга һәм мәдәниятләр һәм милләтләр (этнослар) арасындагы хезмәттәшлекнең уңай тәҗрибәсен танытуга юнәлтелгән проектларга ярдәм күрсәтү.

23. Рус телен Россия Федерациясенең дәүләт теле, туган тел һәм милләтара аралашу теле буларак саклау һәм файдалануны тәэмин итү, рус халкының дәүләт төзүче халык буларак берләштерү ролен ныгыту түбәндәге бурычларны хәл итү юлы белән башкарыла:

а) рус телен Россия Федерациясенең дәүләт теле, туган тел һәм милләтара аралашу теле буларак саклау һәм файдалануны тәэмин итү өчен уңай шартлар тудыру;

б) Россия Федерациясенең дәүләт теле буларак рус телен укытуны камилләштерү һәм аны белү сыйфатын яхшырту;

в) яшьләрнең һөнәри һәм шәхси аралашуда рус әдәби телен файдалануын популярлаштыру, чит тел сүзләрен кирәгеннән тыш файдалануга каршылык күрсәтү;

г) мәгариф, фән һәм мәдәният өлкәсендә рус теленә ярдәм күрсәтүнең төрле формалары өчен шартлар тудыру;

д) рус телен туган тел буларак өйрәнү өчен шартлар тудыру;

е) рус телен һәм әдәбиятын популярлаштыру, җәмгыятьтә тел грамотасы һәм сөйләм культурасы дәрәҗәсен үстерү;

ж) Казанның күренекле лингвистика мәктәбе казанышларына нигезләнеп хәзерге рус әдәби теле кагыйдәләрен үтәүне тәэмин итү мәнфәгатьләрендә фәнни һәм гамәли тикшеренүләр уздыру;

з) вәкилләре Татарстан Республикасында яшәүче Россия халыклары телләрендә иҗат ителгән әсәрләрне рус теленә тәрҗемә итү, шулай ук аларны бастырып чыгару һәм тарату;

и) рус теле тоткан урынны ныгытуга юнәлтелгән мәдәни, белем бирү һәм фәнни-мәгърифәти программаларны, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен (алга таба – «Интернет» челтәрен) файдаланып та, аралашу һәм белем алу өчен рус телендәге интернет-платформаларны һәм онлайн-сервисларны таныту юлы белән гамәлгә ашыру;

к) рус халкының мәдәниятен саклау һәм үстерү өчен уңай шартлар тәэмин итү;

л) рус халкының матди булмаган этник-мәдәни байлыгын саклау һәм үстерү өлкәсендә мәгърифәти, фәнни-тикшеренү, нәшрият проектларын гамәлгә ашыру;

м) рус халкының тарихы һәм мәдәнияте буенча фәнни тикшеренүләр өлкәсендәге эшчәнлеккә ярдәм итү;

н) рус халкының мәдәниятен саклауга һәм үстерүгә юнәлтелгән фестивальләр, конкурслар, күргәзмәләр, ярминкәләр, бәйрәмнәр уздыру, иҗат лабораторияләре, форумнар һәм башка чаралар оештыру;

о) рус халкы мәдәниятен популярлаштыруга ярдәм итә торган һөнәри һәм үзешчән халык иҗаты коллективларына ярдәм күрсәтү;

п) рус теле һәм әдәбияты өлкәсендә фәнни оешмалар һәм белгечләр, язучылар һәм рус матур әдәбияты тәрҗемәчеләре эшчәнлегенә ярдәм итү;

р) мәдәният оешмаларының рус халкы тарихын һәм мәдәниятен популярлаштыруга юнәлтелгән заманча әсәрләр тудыру эшчәнлегенә ярдәм күрсәтү;

с) Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче чит ил гражданнарының рус телен, рус мәдәниятен һәм әдәбиятын белүе дәрәҗәсен күтәрүгә тотрыклы кызыксыну булдыруга ярдәм күрсәтү.

24. Татарстан Республикасының дәүләт теле һәм туган тел буларак татар телен, татар халкы мәдәниятен саклау һәм үстерү түбәндәге бурычларны хәл итү юлы белән тәэмин ителә:

а) татар телен саклау, үстерү һәм аның Татарстан Республикасының дәүләт теле һәм туган тел буларак гамәлдә булуы өчен уңай шартлар булдыру, шул исәптән:

норматив хокукый җайга салынышын камилләштерү;

Татарстан Республикасының дәүләт телләре буларак татар һәм рус телләренең бертигез гамәлдә булуына ярдәм итү;

татар телен укытуны камилләштерү, аны белү сыйфатын яхшырту;

яшьләрнең һөнәри һәм шәхси аралашуда татар әдәби телен файдалануын популярлаштыру, чит тел сүзләрен кирәгеннән тыш файдалануга каршылык күрсәтү;

гражданнарның татар телен өйрәнүе өчен кирәкле матди шартларны һәм оештыру шартларын булдыру;

б) татар теленә һәм мәдәниятенә ярдәм итүнең төрле рәвешләрен куллану өчен шартлар тудыру:

татар телен һәм әдәбиятын популярлаштыру, җәмгыятьнең тел грамотасы һәм сөйләм культурасы дәрәҗәсен үстерү;

хәзерге татар әдәби теле нормаларын үтәүне тәэмин итү мәнфәгатьләрендә фәнни һәм гамәли тикшеренүләр уздыру;

татар халкы язма теле тарихи традицияләренең күчемлелеген саклау;

татар телендә белем бирелә һәм татар теле өйрәтелә торган мәгариф оешмаларын, мәдәният өлкәсе учреждениеләрен, татар телендәге массакүләм мәгълүмат чараларын кадрлар белән тәэмин итүгә, аларның хезмәткәрләренең һөнәри һәм өстәмә һөнәри белем алуын оештыруга ярдәм күрсәтү;

Россия халыклары телләрендә язылган әсәрләрне татар теленә, татар әдәбияты әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итү, шулай ук аларны бастырып чыгару һәм тарату;

татар теле тоткан урынны ныгытуга юнәлтелгән мәдәни, белем бирү һәм фәнни-мәгърифәти программаларны, шул исәптән «Интернет» челтәрен файдаланып аралашу һәм белем алу өчен платформаларны һәм сервисларны таныту юлы белән дә, гамәлгә ашыру;

татар халкының мәдәниятен саклау һәм үстерү өчен уңай шартлар тәэмин итү;

татар халкының матди булмаган этник-мәдәни байлыгын саклау һәм үстерү өлкәсендә мәгърифәти, фәнни-тикшеренү, нәшрият проектларын гамәлгә ашыру;

татар халкының мәдәниятен саклауга һәм үстерүгә юнәлтелгән фестивальләр, конкурслар, күргәзмәләр, ярминкәләр, бәйрәмнәр уздыру, иҗат лабораторияләре, форумнар һәм башка чаралар оештыру;

татар халкы мәдәниятен популярлаштыруга ярдәм итә торган һөнәри һәм үзешчән халык иҗат коллективларына ярдәм күрсәтү;

татар халкының тарихы һәм мәдәнияте, татар теле һәм әдәбияты өлкәсендә фәнни оешмалар һәм белгечләр, язучылар һәм татар матур әдәбияты тәрҗемәчеләре эшчәнлеген тәэмин итү;

мәдәният оешмаларының татар халкы тарихын һәм мәдәниятен популярлаштыруга юнәлтелгән заманча әсәрләр тудыру буенча эшчәнлегенә ярдәм күрсәтү;

татар телен һәм татар әдәбиятын өйрәнү буенча мәгариф программаларын, уку-укыту-методика комплексларын камилләштерү.

25. Татарстан Республикасында яшәүче барлык халыклар вәкилләренең телләрен, мәдәниятләрен һәм гореф-гадәтләрен, Татарстан Республикасында этник-мәдәни күптөрлелекне һәм телләр күптөрлелеген саклау һәм аларга ярдәм күрсәтү, республикада яшәүче халыкларның рухи бердәмлеген ныгыту түбәндәге бурычларны хәл итү юлы белән тәэмин ителә:

Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең телләрен куллану, саклау һәм үстерү өчен уңай шартлар булдыру;

гражданнарның туган телләрен өйрәнүгә хокукларыннан файдалануына ярдәм итү, моның өчен кирәкле шартлар булдыру;

Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләре телләрен файдаланып республикада белем һәм тәрбия бирү системасын үстерү һәм камилләштерү өчен хокукый, матди һәм оештыру шартлары булдыру;

этник-мәдәни күптөрлелекне һәм тел күптөрлелеген саклау һәм үстерүнең нәтиҗәле юлы буларак, мәгариф системасында икетеллелекне һәм күптеллелекне файдалану;

гомуми тарихка һәм мәдәнияткә, дөньяның мәдәни хәзинәләренә хөрмәтле караш тәрбияләү белән бергә, Татарстан Республикасында этник-мәдәни күптөрлелекне һәм тел күптөрлелеген саклау һәм үстерү максатларында белем бирү эшчәнлеге алып баручы оешмаларда белем бирү системасын камилләштерү;

вәкилләре Татарстан Республикасында яшәүче халыклар тарихы, этнологиясе һәм мәдәнияте буенча белгечләргә һөнәри әзерлек бирү системасын камилләштерүдә катнашу;

Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең матди булмаган этник-мәдәни байлыгын, халык сәнгать иҗатын саклау һәм популярлаштыру, халык һөнәрчелеге һәм кәсепчелеген торгызу, саклау һәм үстерүгә ярдәм итү;

вәкилләре Татарстан Республикасында яшәүче халыклар әдәбиятын һәм сәнгать әсәрләрен популярлаштыру һәм тарату, сәнгать күргәзмәләре, фестивальләр, конкурслар, иҗат коллективлары гастрольләре һәм мәдәният өлкәсендә башка чаралар оештыру һәм аларга ярдәм күрсәтү;

милли спорт төрләрен саклау һәм аларга ярдәм күрсәтү;

Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләре телләрендә телевидение һәм радио программалары, аудио һәм видео материаллар эшләүгә, интернет ресурслары булдыруга, басма продукция чыгаруга ярдәм күрсәтү;

фәнни тикшеренүләргә, фәнни-популяр басмаларга, әдәбият һәм сәнгать әсәрләренә, кино һәм телевидение тапшыруларына, халык сәнгать иҗатына, әһәмиятле тарихи вакыйгаларны бәян итә һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең казанышларын пропагандалый торган интернет ресурсларына дәүләт ярдәме күрсәтү һәм аларны популярлаштыру;

Татарстанның этник-мәдәни күптөрлелеген фәнни яктан расланган алымнар нигезендә популярлаштыру максатларында, музейлар һәм мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният истәлекләре) белән танышуны да кертеп, туристлык маршрутларын (төбәк һәм җирле дәрәҗәдәге) һәм экскурсия программаларын формалаштыру һәм таныту.

26. Милләтләр (этнослар) һәм диннәр арасындагы татулыкны һәм тынычлыкны тәэмин итүгә, экстремистлыкка каршы көрәшүгә һәм милли (этник) һәм (яисә) дини җирлектәге низаглы хәлләрне булдырмауга түбәндәге бурычларны хәл итү юлы белән ирешелә:

а) милли (этник) һәм (яисә) дини җирлектә каршылыкларны профилактикалау һәм алдан кисәтү, гражданнарның тигез хокуклылыгын тәэмин итү, шул исәптән:

дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан үзләренең эшчәнлеген алып барганда раса, милли (этник), тел яисә дини билгеләр буенча дискриминацияләүне булдырмау;

эшкә алганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләгәндә, кадрлар резервын формалаштырганда расасына, нинди милләттән (этностан) булуына, теленә, дингә мөнәсәбәтенә карамастан, кеше һәм гражданның хокуклары һәм ирекләре бертигезлеген тәэмин итү;

милләтләр (этнослар) һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләр өлкәсендә куркынычларга каршы гамәл кылу мәсьәләләре буенча ведомствоара хезмәттәшлекнең нәтиҗәлелеген арттыру;

Татарстан халкын читтән кергән фикерләр, рухи-әхлакый хәзинәләр таралудан һәм начар нәтиҗәләргә китерә торган мәгълүмати-психологик йогынтылардан саклау, экстремистлык продукциясе таралуын булдырмау;

экстремистлык чагылышларын, дини, милли радикаллыкның таралуын кисәтүгә юнәлдерелгән мәгърифәти чаралар уздыру;

гражданнарның ирекле рәвештә үз милләтен (этносын) билгеләве өчен булдырылган шартларны, шул исәптән Бөтенроссия халык санын исәпкә алу вакытында да, саклау;

дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруда катнаша торган коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлегенә ярдәм күрсәтү;

чит ил дәүләтләренең һәм аларның гражданнарының Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы мәнфәгатьләренә зыян салу максатында коммерциячел булмаган оешмаларга һәм юридик зат булмаган иҗтимагый берләшмәләргә йогынты ясау омтылышларын булдырмау;

милләтләр һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләр өлкәсендә мониторинг уздыру һәм Татарстан Республикасында дини һәм милли җирлектә низагларны алдан кисәтү системасын камилләштерү;

миграция өлкәсендә бурычларны хәл иткәндә дәүләт милли сәясәте максатларын һәм бурычларын исәпкә алу;

б) чит ил гражданнарын Россия җәмгыятендә яшәү шартларына җайлаштыруга ярдәм итү механизмнарын камилләштерү, шул исәптән:

Татарстан Республикасында чит ил гражданнарының, шул исәптән аларның балигъ булмаган балаларының, яшәү шартларына җайлашуы өчен, аларның рус телен яхшы өйрәнүенә, республиканың социаль, тарихи һәм милли-мәдәни үзенчәлекләрен исәпкә алып, Россия җәмгыятендә гомуми кабул ителгән үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен (көнкүреш кагыйдәләре, дини йолаларны башкару) үтәвенә, аларда Россия җәмгыятенә хас хокукый аң һәм хокукый культура формалаштыруга, аларны Россиянең традицион рухи-әхлакый хәзинәләренә якынайтуга ярдәм итә торган шартлар булдыру;

чит ил гражданнарының социаль һәм мәдәни яктан Татарстан Республикасында яшәү шартларына җайлашуына ярдәм итүне тәэмин итә торган инфраструктура (җайлашу үзәкләре) формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтү;

чит ил гражданнарын Татарстан Республикасында яшәү шартларына җайлаштыруга ярдәм итү программаларын, шул исәптән дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнарының, чит ил гражданнарын эшкә җәлеп итә торган эш бирүчеләрнең, белем бирү эшчәнлеген тормышка ашыра торган оешмаларның һәм граждан җәмгыяте институтларының хезмәттәшлеге нигезендә хезмәт мигрантлары өчен җайлашу мәсьәләләренә кагылышлы курсларны эшләү һәм гамәлгә ашыру;

чит ил гражданнарын Россия Федерациясендә яшәү шартларына җайлаштыруга ярдәм итә торган барлык субъектларның, дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнарының, чит ил гражданнарын эшкә җәлеп итә торган эш бирүчеләрнең, белем бирү эшчәнлеген тормышка ашыра торган оешмаларның һәм граждан җәмгыяте институтларының хезмәттәшлеген камилләштерү;

Татарстан Республикасында чит ил гражданнарының социаль аерымлануын һәм җирлектә сегрегацияләнүен булдырмау, моңа этәргеч бирә торган шартларны бетерү;

в) граждан җәмгыяте институтларының дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашуын тәэмин итү, шул исәптән:

граждан җәмгыяте институтларын, шул исәптән яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләрен гражданнар бердәмлеген ныгыту, милләтара (этносара) мөнәсәбәтләрне гармонияләштерү һәм экстремистлыкны профилактикалау, милли (этник) һәм (яисә) дини җирлектә низагларны кисәтү буенча чаралар уздыруга җәлеп итү;

дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары карамагындагы иҗтимагый советлар һәм башка консультация органнары, гомумроссия гражданлык тәңгәллеген (гражданлык үзаңын) ныгыту, милләтләр (этнослар) һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләрне гармонияләштерү, чит ил гражданнарын Татарстан Республикасында яшәү шартларына җайлаштыруга ярдәм итү буенча эксперт советлары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру;

дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнарының дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлегенә карата Россия Федерациясе һәм

Татарстан Республикасы законнарында каралган җәмәгать контроле механизмнарыннан файдалану;

граждан җәмгыяте институтлары тарафыннан эшләнгән дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән проектларны финанслау чыганакларының, шулай ук әлеге проектларны гамәлгә ашыру нәтиҗәләренең ачыклыгын тәэмин итү;

милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендә коммерциячел булмаган оешмаларның проект эшчәнлегенә ярдәм итү;

гомумроссия гражданлык тәңгәллеген (гражданлык үзаңын) ныгыту, милләтләр (этнослар) һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләрне гармонияләштерү, Татарстан Республикасында чит ил гражданнарын социаль һәм мәдәни шартларга җайлаштыру, шулай ук экстремистлыкны профилактикалау, милли һәм дини җирлектә низагларны кисәтү эшендә «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы (алга таба – Татарстан халыклары ассамблеясе), «Бөтендөнья татар конгрессы» төбәкара иҗтимагый оешмасы, «Татарларның федераль милли-мәдәни мохтарияте» иҗтимагый оешмасы, социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлегенә ярдәм итү;

этник-мәдәни инфраструктураны: халыклар дуслыгы йортларын, милли мәдәният үзәкләрен, эшчәнлекләре дәүләт милли сәясәте мәсьәләләрен хәл итүгә юнәлтелгән башка дәүләт оешмаларын һәм муниципаль оешмаларны үстерү;

дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән волонтерлык (ихтыярыйлык) эшчәнлегенә булышлык итү.

27. Татарстанны татар халкының рухи һәм этник-мәдәни үзәге буларак таныту, Татарстан Республикасыннан читтә яшәүче татарларны интеллектуаль, икътисадый һәм этник-мәдәни яктан берләштерү һәм аларга ярдәм итү өчен шартлар булдыру түбәндәге бурычларны хәл итү юлы белән тәэмин ителә:

Татарстан Республикасыннан читтә яшәүче татарларга туган телне, мәдәниятне, гореф-гадәтләрне һәм милли тәңгәллекне саклауда ярдәм итү;

Россия Федерациясендә татар берләшмәләренең үз этник-мәдәни хокукларын тәэмин итү, татар халкының рухи һәм этник-мәдәни үзәге – Татарстан белән элемтәләрне саклау буенча эшчәнлеген берләштерүгә ярдәм итү;

татарлар күпләп яши торган Россия Федерациясе субъектлары, ерак һәм якын чит илләр һәм чит ил диаспоралары белән, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итүгә булышлык күрсәтү максатларында даими нигездә мәдәни һәм икътисадый элемтәләрне саклау һәм үстерү;

Татарстан Республикасыннан читтә яшәүче татарларга Татарстан Республикасының татар милли-мәдәни иҗтимагый берләшмәләре белән

элемтәләрне киңәйтү аша милли-мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерүдә ярдәм күрсәтү;

татарлар яши торган территорияләрдә күрсәтү өчен татар телендә телевидение программалары булдыру.

28. Чит илләрдә яшәүче ватандашларыбызга, аларның Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы белән элемтәләрен үстерүгә һәм Россия Федерациясенә (Татарстан Республикасына) үз ихтыяры белән күчеп килүенә булышлык итү түбәндәге бурычларны хәл итү юлы белән тәэмин ителә:

а) Россия Федерациясен объектив рәвештә кабул итүгә, күпмилләтле Россия мәдәниятен чит илләрдә популярлаштыруга ярдәм итү;

б) чит илләрдә яшәүче ватандашларыбызның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итүгә, аларның Россия мәдәниятенә, теленә тәңгәллеген һәм Россиянең традицион рухи-әхлакый хәзинәләрен саклавына ярдәм итү;

в) раса, милли, тел яисә дини билгеләр буенча дискриминацияләүне, гражданнар ирегеп шәрехләүдә ике төрле стандартлар кертүне булдырмау максатларында чит илдәге ватандашларга кагылышлы дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча халыкара дәүләтара һәм хөкүмәтнеке булмаган оешмалар белән Россия Федерациясе мәнфәгатьләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә үзара эшчәнлек алып бару;

г) неонацизм, русофобия, расизм, ксенофобия очракларына, шулай ук дөнья сәясәтендә каршылыкны көчәйтү һәм реваншизм максатларында тарихны бозып күрсәтүгә, Икенче бөтендөнья сугышы нәтиҗәләрен яңача бәяләү омтылышларына, совет халкының 1941–1945 еллар Бөек Ватан сугышындагы батырлыгының әһәмиятен киметеп күрсәтүгә каршы юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыруга ярдәм итү;

д) чит илләрдә яшәүче ватандашлар иҗтимагый оешмаларының массакүләм мәгълүмат чаралары, «Интернет» челтәрен дә кертеп, аларның мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендәге ресурслары белән хезмәттәшлек итү.

29. Дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруны мәгълүмати тәэмин итү массакүләм мәгълүмат чаралары һәм җәмәгатьчелек фикере лидерлары катнашында түбәндәге бурычларны хәл итү юлы белән башкарыла:

а) дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру мәсьәләләрен бәян итә, шулай ук Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның туган телләрендә материаллар бастыра торган массакүләм мәгълүмат чараларына ярдәм итү;

б) гражданнар бердәмлеген ныгытуга, милләтара (этносара) мөнәсәбәтләрне гармонияләштерүгә, вәкилләре Татарстан Республикасында яши торган халыклар мәдәниятен, Россиянең традицион рухи-әхлакый һәм мәдәни-тарихи хәзинәләрен популярлаштыруга һәм аларны яшьләр арасында таныттуга, экстремистлык идеологиясен пропагандалауга каршы торуга һәм

тышкы тискәре мәгълүмати-психологик йогынтыдан саклануга юнәлдерелгән социаль әһәмияткә ия контент булдыру һәм аны киңрәк тарату өчен массакүләм мәгълүмат чараларының, «Интернет» челтәре ресурсларының, шул исәптән социаль челтәрләрнең, видеохостингларның, мессенджерларның һәм блогларның мөмкинлекләреннән файдалану;

в) дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән социаль реклама әзерләү һәм аны массакүләм мәгълүмат чараларында, «Интернет» челтәрен дә кертеп, мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә урнаштыру;

г) дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру мәсьәләләре турында язучы журналистларга һөнәри белем бирүне һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыруга булышлык итү;

д) массакүләм мәгълүмат чараларында, «Интернет» челтәрен дә кертеп, мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә милләтләр (этнослар) һәм диннәр арасындагы хезмәттәшлек мәсьәләләре турында иң яхшы язмаларга конкурслар оештыру һәм уздыру.

## IV. Дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнарының дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруы

30. Дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнарының дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруы Россия Федерациясенең 2036 елга кадәр дәүләт милли сәясәте стратегиясенә һәм Концепциягә яраклы рәвештә дәүләт милли сәясәте максатларына ирешүгә комачаулык итә торган куркынычлы очраклар килеп чыгу белән бәйле үзенчәлекләрне исәпкә алып, дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнарының түбәндәге алымнар нигезендә килешенгән гамәлләре нәтиҗәсендә тормышка ашырыла:

а) дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары Татарстан Республикасында һәм тәгаен муниципаль берәмлекләрдә яши торган халыклар вәкилләренең үзара эшчәнлеге турында тарихи тәҗрибәгә, гомумроссия гражданлык тәңгәллеге (гражданлык аңы) һәм аның контекстында формалаштырыла торган Татарстан гражданлык тәңгәллеге формалаштыруга йогынты ясаган әһәмиятле төбәк күләмендәге вакыйгалар турында хәтергә таяна;

б) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясендә республикада яши торган халыклар вәкилләренең этник-мәдәни үзенчәлеген саклау һәм аларның хокукларын яклау күздә тотыла, стратегик планлаштыру буенча республика документлары һәм муниципаль документлар дәүләт милли сәясәтенең өстенлекле юнәлешләрен һәм аны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган бурычларны исәпкә алып эшләнә һәм тормышка ашырыла;

в) дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары гражданлык бердәмлеген һәм бердәм мәдәни киңлекне ныгыту, вәкилләре республикада

яши торган халыкларның этник-мәдәни күптөрлелеген, телләрен һәм мәдәниятләрен саклау һәм үстерү, Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының социаль һәм мәдәни шартларга җайлашуы, милли (этник) һәм (яисә) дини җирлектә низагларны профилактикалау чараларын күрә;

г) дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары гомумроссия гражданлык тәңгәллеген (гражданлык аңын) ныгытуга, гражданнарга патриотик тәрбия бирүгә, экстремистлык омтылышларын һәм милли (этник) һәм (яисә) дини җирлектә низагларны профилактикалауга юнәлдерелгән республика һәм муниципаль дәрәҗәдәге белем бирү, мәдәни, мәгърифәти, нәшрият программаларын һәм башка программаларны килештерүнең нәтиҗәлелеген арттыру чараларын күрә;

д) дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары милли (этник) һәм (яисә) дини җирлектә низагларны мониторинглауны һәм профилактикалауны тәэмин итә;

е) милләтләр һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләр буенча консультация-киңәшмә органнары дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнарының, коммерциячел булмаган оешмаларның, шул исәптән фәнни һәм эксперт берләшмәләренең Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча үзара эшчәнлек алып баруын тәэмин итә;

ж) граждан җәмгыяте институтларын дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруга җәлеп итү, бу исә илнең территориаль бөтенлеген, республикада сәяси һәм социаль тотрыклылыкны тәэмин итүгә, шулай ук милли (этник) һәм (яисә) дини җирлектә низагларны, экстремистлык омтылышларын профилактикалау һәм кисәтүгә юнәлдерелгән чараларның нәтиҗәлелеген арттыруга ярдәм итә;

з) граждан җәмгыяте институтларының дәүләт милли сәясәте максатларына ирешүгә һәм аның өстенлекле юнәлешләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән башлангычларына, шул исәптән әлеге башлангычларны тормышка ашыруда дәүләт милли сәясәте өлкәсендә эшчәнлек алып баручы дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр һәм оешмаларның катнашуын тәэмин итү, шулай ук грант программаларын гамәлгә ашыру юлы белән дә, ярдәм итү.

## V. Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру инструментлары һәм механизмнары

31. Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру инструментлары түбәндәгеләр:

а) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары;

б) федераль, республика һәм муниципаль дәрәҗәләрдә эшләнгән стратегик планлаштыру документлары һәм аларны гамәлгә ашыру планнары, түбәндәгеләрне дә кертеп:

«Дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» Россия Федерациясе дәүләт программасын, Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәтенең аерым юнәлешләре белән бәйле башка дәүләт программаларын;

Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру», «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү», «Татар халкының милли тәңгәллеген саклау» дәүләт программаларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт милли сәясәтенең аерым юнәлешләрен гамәлгә ашыру белән бәйле башка Татарстан Республикасы дәүләт программаларын;

Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре программаларын;

в) милләтләр һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләр өлкәсен мониторинглау һәм низаглы хәлләрне алдан кисәтү буенча федераль дәүләт мәгълүмат системасы;

г) «Татарстан Республикасында милләтләр һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләрне мониторинглау һәм дини һәм милли җирлектә низаглы хәлләрне алдан кисәтү комплекслы системасы» дәүләт мәгълүмат системасы;

д) Татарстан Республикасы дәүләт телләренең һәм Татарстан Республикасында яшәүче башка халыклар вәкилләре телләренең торышын һәм аларга ярдәм чараларын мониторинглау.

32. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасында 2036 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең дәүләт милли сәясәте стратегиясен гамәлгә ашыру буенча чаралар планын эшли һәм раслый.

33. Концепция иҗтимагый берләшмәләр, фәнни һәм башка оешмалар белән үзара эшчәнлек алып баруга компетенцияләре нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

34. Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының, гражданлык җәмгыяте институтларының килешенгән эшчәнлек алып баруы, Концепция нигезендә эшләнгән сәяси, хокукый, оештыру, социаль-икътисадый, мәгълүмати һәм башка чараларны гамәлгә ашыру ярдәмендә тәэмин ителә.

35. Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру һәм камилләштерү мәсьәләләре, Татарстан Республикасында милләтләр (этнослар) һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләрнең торышы Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Милләтләр һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләр советы тарафыннан карап тикшерелә.

36. Дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнарының, иҗтимагый берләшмәләрнең, фәнни һәм башка оешмаларның Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру өлкәсендә

эшчәнлеген килештерү чаралары Татарстан Республикасында милләтләр һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләр мәсьәләләре буенча ведомствоара эш төркеме тарафыннан кабул ителә.

37. Татарстан Республикасы Рәисе карары нигезендә дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруның аеруча актуаль мәсьәләләре Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, Татарстан халыклары ассамблеясе, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы киңәшмә һәм консультация органнары вәкилләре катнашында Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы утырышларында карап тикшерелергә мөмкин.

38. Концепцияне гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, муниципаль норматив хокукый актлар кабул ителергә, шулай ук төбәкара килешүләр төзелергә мөмкин.

39. Концепцияне гамәлгә ашыруны республика һәм муниципаль дәрәҗәләрдә мәгълүмати тәэмин итү кызыксыну белдергән дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары, дәүләт фәнни һәм мәгариф оешмалары, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм этник-мәдәни юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмаларның мәгълүмат ресурсларын җәлеп итү юлы белән башкарыла.

40. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты:

а) республикада милләтара (этносара) мөнәсәбәтләрнең торышын, дәүләт милли сәясәте бурычларын гамәлгә ашыру буенча дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү мөмкинлеге бирә торган характеристикаларны (индикаторларны) эшләүне һәм раслауны оештыра;

б) Концепциянең үтәлешен контрольдә тота һәм ел саен Татарстан Республикасы Рәисенә аның үтәлеше турында мәгълүмат бирә.

41. Концепция дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру барышында килеп чыккан бурычларны хәл итү кирәклеген, Татарстан Республикасының социаль-икътисадый һәм мәдәни үсеше торышын һәм перспективаларын исәпкә алып, 2036 елга кадәр Россия Федерациясенең дәүләт милли сәясәте стратегиясе нигезендә үзгәртелә.

## VI. Концепцияне гамәлгә ашырудан көтелә торган нәтиҗәләр

42. Концепцияне гамәлгә ашырудан көтелә торган нәтиҗәләр:

а) гражданнар бердәмлеген, гомумроссия гражданлык тәңгәллеген һәм аның контекстында формалаштырыла торган Татарстан гражданлык тәңгәллеген ныгыту, шулай ук Россия Федерациясенең бердәм мәдәни киңлеген формалаштыру;

б) рус телен Россия Федерациясенең дәүләт теле, туган тел, милләтләр арасында аралашу теле буларак саклау һәм файдалануны тәэмин итү;

в) татар телен Татарстан Республикасының дәүләт теле, туган тел буларак саклау һәм үстерү, татар халкының мәдәниятен саклау һәм үстерү;

г) Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында яши торган халыкларның туган телләрен саклау, үстерү, шулай ук өйрәнү һәм яклау өчен шартлар тудыруны тәэмин итү;

д) Татарстан Республикасында яши торган халыклар вәкилләренең этник-мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен шартлар тудыруны тәэмин итү;

е) милләтләр (этнослар) һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләр өлкәсендә низаглы хәлләрне булдырмау, булган очракта, тыныч юл белән хәл итү;

ж) Татарстан Республикасында чит ил гражданнарының социаль һәм мәдәни шартларга җайлашуы һәм аларны Россия җәмгыятенең бер өлеше итеп тану, Татарстан Республикасында чит ил гражданнарының социаль аерымлануын һәм җирлектә сегрегацияләнүен булдырмау;

з) Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру кысаларында төбәкара хезмәттәшлекнең нәтиҗәлелеген арттыру һәм халыкара элемтәләрне үстерү.

43. Концепцияне гамәлгә ашыру нәтиҗәләре 2036 елга кадәр Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте стратегиясен гамәлгә ашыруның максатчан күрсәткечләре кысаларында бәяләнә.

44. Концепцияне гамәлгә ашыру Россия Федерациясенең күпмилләтле халкының бердәмлеген, дәүләтнең бердәмлеген, Россия Федерациясенең бөтенлеген ныгытуга, республиканың ныклы үсешен, шулай ук аның социаль һәм икътисадый тотрыклылыгын тәэмин итүгә ярдәм итәргә тиеш.

---